ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧЫБЫКЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

№ 141 27 ноябрь 2024 ел.

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авылҗирлеге Советының 2018 елның 10 сентябрдәге №112 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге территориясендә транспорт инфраструктурасын комплексы үстерү программасына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирлекләрнен, муниципаль округларның, шәһәро кругларының транспорт инфраструктурасын комплексы үстерү программаларына таләпләрне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы карары, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия ФедерациясеХөкүмәтенең 2024 елның 23 маендагы 643 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Чыбыклы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 сентябрдәге №112 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге территориясендә транспорт инфраструктурасын комплексы үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа эчтәлегенә "җәяүлеләр һәм велосипедта йөрү шартларына характеристика» сүзләрен «велосипедчылар, җәяүлеләр һәм хәрәкәт өчен индивидуаль мобильлек чараларын кулланучы затларның хәрәкәт шартларына характеристика»сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1.7 пунктта:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәя нитәргә:

«1.7. Велосипедчылар, җәяүлеләр һәм хәрәкәт өчен индивидуаль мобильлек чараларын кулланучы затларның хәрәкәт шартларына характеристика»;

б) бишенче абзацта икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәянитәргә: «Велосипедчыларның һәм индивидуаль мобильлек чараларын хәрәкәт итү өчен файдаланучы затларның хәрәкәте гомуми файдаланудагы юллар буйлап юл йөрү кагыйдәләре таләпләрен игезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлег екарарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының «Авыл җирлекләре» рәсми сайты бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Чыбыклы авылҗирлеге Советы Рәисе И.Н. Гадершин